**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР № 11**

Кече Урыссу ав. «01» декабрь 2025 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 маендагы 7 санлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланган вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, 2009 елның 12 февралендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында»гы 15-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы 182 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 228 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 маендагы 7 санлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланган вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 бүлегенең 3 пунктында «12,86» санын «15,48» санына алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 1 пунктында «13 990» санын «15 389» санына алмаштырырга;

1.3. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 6 пунктында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга.;

1.4. Нигезләмәнең 3 бүлегенең 1 пунктындагы 6 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга.;

1.5. Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын урнаштырырга. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Н.С.Рәфыйков

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 маендагы 7 санлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланган вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә
1 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфа атамалары | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | шәһәр тибындагы бистәләр нигезендә төзелгән авыл һәм шәһәр җирлекләрендә |
| | 12 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 21 091 |